МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.04.2017 Казан шәһәре № под-610/17

Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015-2025 елларга Татарстан Республикасында укучыларга тәрбия бирүне үстерү стратегиясен раслау турында 2015 елның 17 июнендәге 443 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, шәхесне үстерүдә тәрбия, өстәмә белем бирүнең ролен арттыру максатларында б о е р а м:

1. Тәрбия һәм балаларга өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре Грантын гамәлгә куярга.

2. Расларга:

2.1. Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр грантын алуга конкурс оештыру һәм үткәрү буенча календарь план.

2.2. Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты турында Положение.

3. Балаларга өстәмә белем бирү бүлегенә (Ж. В. Соркина) өстәмә белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесе Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге (Р. А. Идрисов), Росток Республика психологик-педагогик ярдәм үзәге дәүләт автоном белем бирү учреждениесе (Т. Н. Бәширова) белән берлектә Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары мәгариф оешмаларында грант турындагы Положение нигезендә эшне оештырырга.

5. Балаларга өстәмә белем бирү бүлегенә (Ж. В. Соркина) боерык кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә

6. Әлеге приказның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Л.О.Сулимага йөкләргә

Министр урынбасары А.И. Поминов

Расланган
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2017 елның 10 апрелендәге № под-610/17 боерыгы белән

Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр грантын алуга конкурс оештыру һәм үткәрү буенча календарь план

| № | Чара | Үтәлеш вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Грантны оештыру һәм уздыру мәсьәләсе буенча киңәшмә | 2017 ел Февраль | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 2. | Өстәмә белем бирү оешмалары директорлары киңәшмәсендә конкурс шартлары турында фикер алышу | 2017 ел Март | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы |
| 3. | Татарстан Республикасы муниципаль районнары башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре(идарәләре) башлыклары белән киңәшмә | 2017 ел Апрель | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе сайтларында грантлар турында норматив-методик материаллар урнаштыру | 2017 май | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, ДБУ РЦВР |
| 5. | ДБУ РЦВР һәм «Росток «психологик ярдәм республика үзәге (алга таба ЦППРК)» дәүләт автоном белем бирү учреждениесендә грант алырга теләүчеләрне теркәү | 2017 елның 10 июненә кадәр | ДБУ РЦВР, ЦППРК |
| 6. | 2017 елда грант алырга теләүчеләрнең конкурс материалларына техник экспертиза | 2017 ел, 11-12 июнь | ДБУ РЦВР, ЦППРК |
| 7. | Грант алырга теләүчеләрнең конкурс материалларына эксперт | 2017 елның | РЦВР ДББУ Эксперт комиссияләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бәяләре | 13 23 июне | |
| 8. | Грант алучылар исемлеген төзү | 2017 елның 26 30 июне | ГБУ «РЦВР», ЦППРК, Республика конкурс комиссиясе |
| 9. | Апелляция | 2017 елның 3 25 июле | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Республика конкурс комиссиясе |
| 10. | Сайтта Грант алучыларның расланган исемлеген урнаштыру | 2017 ел 26 июль | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы, ГБУ «РЦВР», |

Расланган
Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2017 елның 10 апрелендәге № под-610/17 боерыгы белән

**Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты турында**
**Положение**

## 1. Гомуми положениеләр

1.1. Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты (алга таба Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела.

Грантның максаты белем алучы шәхесне үстерүдә, аны рухи-әхлакый баетуда һәм тормышта үзбилгеләнүгә әзерләүдә тәрбия, өстәмә белем бирүнең ролен арттыру, педагоглар, ата-аналар, укучыларны социальләштерүнең башка субъектлары арасында хезмәттәшлекне үстерү.

1.2. Грантның бурычлары:

гомуми белем бирү, өстәмә белем бирү, һөнәри белем бирү, муниципаль мәгариф идарәләренең дәүләт бюджет оешмаларының, балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә белем бирү, методик һәм җитәкчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы иң яхшы хезмәткәрләрен ачыклау һәм кызыксындыру;

балаларга тәрбия, өстәмә белем бирү системасында педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләрнең хезмәтенең дәрәҗәсен һәм һөнәри осталыгын күтәрү;

Татарстан Республикасында балаларга тәрбия, өстәмә белем бирү системасында нәтиҗәле тәҗрибәне ачыклау һәм тарату.

1.3. Грантта катнашучылар:

Грант бирүче грант бирү вәкаләтләрен башкаручы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба министрлык).

Грант алучы әлеге Положениенең 1.4 пунктында билгеләнгән таләпләргә һәм әлеге Положениенең 2 бүлегендә билгеләнгән критерийларга туры килә торган,

грант алуга конкурс сайлап алуы узган физик зат. Грант алучылар республика комиссиясе тарафыннан билгеләнә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

Мөрәҗәгать итүче грантта катнашырга теләүчеләрне тәкъдим итүче мәгариф оешмасының үзидарә органнары ( Попечительләр советы, гомуми җыелыш, педагогик совет, мәгариф оешмасы уставында каралган башка үзидарә органнары); һөнәри педагогик ассоциацияләр яисә берләшмәләр, (профильле методик берләшмәләр, белем бирү технологияләре буенча ассоциацияләр, профессиональ союзлар), дәүләт бюджет оешмалары (балалар йортлары, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаилә коруга ярдәм итү үзәкләре), муниципаль мәгариф идарәсе органнары

1.4. Грантка дәгъва кылучылар сыйфатында түбәндәге таләпләргә җавап бирә торган педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләр катнаша ала:

педагогик эшчәнлек стажы кимендә өч ел;

эш урыны, законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, гомуми белем бирү оешмасы, өстәмә белем бирү оешмасы, һөнәри белем бирү оешмасы, дәүләт бюджет оешмасы (балалар йорты, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаилә коруга ярдәм итү үзәге), мәгариф идарәсенең муниципаль органы.

1.5. Грант түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

Өстәмә белем бирү оешмасының иң яхшы директоры;

Өстәмә белем бирүнең иң яхшы педагогы;

Өстәмә белем бирүнең иң яхшы методисты;

Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр (тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсе кадрларының һөнәри осталыгы буенча) Кеше тәрбияләү һәм Йөрәгемне балаларга бирәм профессиональ осталык республика конкурслары кысаларында);

Иң яхшы педагог-оештыручы;

Психологик-педагогик хезмәтнең иң яхшы педагог-психологы;

Белем бирү оешмасының, дәүләт бюджет оешмасының иң яхшы педагог-психологы;

Һөнәри белем бирү оешмасы директорының тәрбия эшләре буенча иң яхшы урынбасары.

1.1. Грант  25 000, 30 000, 50 000 сум күләмендә премия рәвешендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Грант шәхси, өченче физик затларга тапшырыла алмый.

Грант алучы өч елга 1 тапкыр грантта катнашырга хокуклы.

1.6.1. Грантлар саны елына 324 Гранттан артмый.

1.6.2. Грантлар саны түбәндәгечә бүленә:

Өстәмә белем бирү оешмасының иң яхшы директоры номинациясендә 2016 2017 уку елында өстәмә белем бирү оешмаларының рейтинглаштыру нәтиҗәләре буенча 50 000 сум күләмендә 14 грант бирелә.

Иң яхшы өстәмә белем бирү педагогы номинациясенә 170 грант бирелә, һәм алар саны түбәндәгечә бүленә:

2017 елда Созвездие-Йолдызлык

эстрада сәнгате ачык республика телевизион яшьләр фестивалендә җиңүчеләрне әзерләгән педагогларга 50 000 сумлык 30 грант бирелә;

өстәмә белем бирү педагогларына 50 000 сум күләмендә, өстәмә белем бирүнең  түбәндә билгеләнгән һәр юнәлешендә катнашучылар санына бәйле  140 грант бирелә:

сәнгать;

туристлык-туган якны өйрәнү;

физкультура-спорт;

техник;

табигать белеме;

социаль-педагогик.

«Өстәмә белем бирүнең иң яхшы методисты» номинациясенә 50 000 сум күләмендә 15 грант бирелә.

«Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» номинациясенә (тәрбия һәм балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә кадрларның һөнәри осталыгы буенча «Кеше тәрбияләү» һәм «Йөрәгемне балаларга бирәм»

республика конкурслары кысаларында) 50 000 сумнан 12 грант (1,2,3 урын), 25 000 сумнан 28 грант (лауреатлар) бүлеп бирелә.

«Иң яхшы педагог-оештыручы» номинациясенә 50 000 сум күләмендә 30 грант бирелә.

«Психологик-педагогик хезмәтнең иң яхшы педагог психологы (ППМ Үзәк)» номинациясенә 50 000 сум күләмендә 15 грант бирелә.

«Белем бирү оешмасының, дәүләт бюджет оешмасының иң яхшы педагог-психологы» номинациясенә 30 000 сум күләмендә 25 грант бирелә.

«Һөнәри белем бирү оешмасының тәрбия эше буенча иң яхшы директор урынбасары» номинациясенә 2016-2017 уку елында һөнәри белем бирү оешмаларының рейтинг нәтиҗәләре буенча 50 000 сум күләмендә 15 грант бирелә.

Грантны түләү грантны алуга конкурс сайлап алуы нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

## 2. Грант алуга конкурс сайлап алу критерийлары

2.1. «Өстәмә белем бирү оешмасының иң яхшы директоры» номинациясендә өстәмә белем бирү оешмаларында иң яхшы директорларын Грант алуга конкурс сайлап алуы 2016-2017 уку елында өстәмә белем бирү оешмаларының рейтинглау нәтиҗәләре нигезендә, түбәндәге критерийлар буенча алып барыла:

муниципаль берәмлектә укучыларның гомуми санынннан. өстәмә белем бирү оешмасында укучылар өлеше ( % );

агымдагы елда өстәмә белем бирү оешмасы берәмлекләрендә укучылар контингентының сакланышы;

өстәмә белем бирү оешмасы эшчәнлегенең ачыклыгы: өстәмә белем бирү оешмалары сайтларының торышы;

өстәмә белем бирү оешмасының матди-техник яктан тәэмин ителеше дәрәҗәсе:

агымдагы уку елында өстәмә белем бирү оешмасының һәм педагогик хезмәткәрләрнең грант активлыгы;

агымдагы уку елында бюджеттан тыш акчаларны җәлеп итү;

дәүләт-шәхси партнерлык;

физик мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, инвалид балаларга өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү процессын гамәлгә ашыру өчен җиһазланыш дәрәҗәсе

якындагы территориядә яшәүче халык (население) өчен өстәмә белем бирү оешмасының белем бирү хезмәтләрен киңәйтү:

физик мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, инвалид балалар өчен гамәлгә ашырыла торган, яраклаштырылган өстәмә гомуми белем бирү программалары саны;

өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда кулланылган дистанцион белем бирү технологияләре саны;

өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенең компетентлыгы дәрәҗәсе:

өстәмә белем бирү оешмаларының директорлар Советы эшчәнлегендә катнашуы;

җитәкче вазифасы буенча профессиональ конкурсларда катнашуы;

өстәмәмә белем бирү оешмасының белем бирү оешмалары арасында уздырылган конкурсларда катнашуы;

эксперт эшчәнлеге (жюри әгъзасы, эксперт комиссиясе әгъзасы һәм тли);

өстәмә белем бирү оешмасы педагогларының һөнәри осталык дәрәҗәсе:

педагогик хезмәткәрләрнең эшчәнлек юнәлешләре буенча стажировкаларда, мастер-классларда, семинарларда, конференцияләрдә катнашуы;

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри конкурсларда катнашу нәтиҗәлелеге;

педагогларның мөмкинлекләре чикләнгән балаларга, инвалид балаларга өстәмә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә торган махсус белеме булу;

өстәмә белем бирү оешмаларында укучыларның әзерлек дәрәҗәсе:

укучыларның аларның дәрәҗәсен исәпкә алып уздырылган конкурс чараларында катнашу нәтиҗәләре;

өстәмә белем бирү оешмасында белем алучы физик мөмкинлекләре чикләнгән балалар, инвалид балалар саны;

өстәмә белем бирү оешмасының оештыру-методик активлыгы:

белем бирү оешмасы тарафыннан республика, бөтенроссия, халыкара чаралар оештыру һәм үткәрү;

өстәмә белем бирү оешмасында белем бирү сыйфатына бәйсез бәя бирү.

2.2. «Өстәмә белем бирү буенча иң яхшы педагог» номинациясендә грантка дәгъва итүче өстәмә белем бирү буенча иң яхшы педагогларны конкурс нигезендә сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

агымдагы елда әлеге педагогик хезмәткәрнең берләшмәләрендә укучылар контингентының сакланышы;

укучыларның соңгы өч елда төрле дәрәҗәдәге конкурс чараларында, фестивальләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашуын тәэмин итү;

укучыларның соңгы өч елда төрле дәрәҗәдәге конкурс чараларында катнашу нәтиҗәлелеге;

педагогик хезмәткәрнең инновацион эшчәнлектә катнашуы, эксперименталь эш алып бару, методик кулланмалар эшләү һәм яңа өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә кертүе;

педагогик хезмәткәрнең соңгы өч елда төрле дәрәҗәдәге һөнәри бәйгеләрдә катнашу нәтиҗәлелеге;

берләшмәне үстерүгә грантлар җәлеп итү;

педагогик хезмәткәрнең соңгы өч елда үз педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү буенча (чыгышлар һәм публикацияләр) чараларда (фәнни-гамәли конференөияләр, семинарлар, мастер-классалр) катнашуы

2.2.1. 2017 елда «Созвездие-Йолдызлык» эстрада сәнгате ачык республика телевизион яшьләр фестивалендә җиңүчеләрне әзерләгән өстәмә белем бирү педагогларын сайлап алу конкурсы түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

грант алучының тәрбияләнүчеләре арасында 2017 елда «Созвездие-Йолдызлык» фестиваленең жюри әгъзаларының йомгаклау беркетмәсе нигезендә бирелгән; «Вокал-соло (1 нче кечкенәләр төркеме)», «Вокал-соло (2 нче кечкенәләр төркеме*)»,*»Вокал-соло (урта төркем (кызлар)», «Вокал-соло» (урта төркем (малайлар)Я», «Вокал-соло (өлкән төркем)», «Вокаль ансамбльләр (кече төркем)»,

«Вокаль ансамбльләр (урта төркем)», « Вокаль ансамбльләр (өлкән төркем)», « Хореография (кече төркем)», « Хореография (кече төркем)», «Хореография (урта төркем)», «Хореография (өлкән төркем)», «Конферанс (кече төркем)», « Конферанс» (урта төркем)», «Конферанс» (зурлар төркеме)», « Хореография (зурлар төркеме)» номинацияләрендә беренче призлы урыннарны алуы.

грант алучының тәрбияләнүчеләре арасында «Созвездие-Йолдызлык» фестиваленең «Вокал-соло (1 нче кечкенәләр төркеме)», «Вокал-соло (2 нче кечкенәләр төркеме), Вокал-соло (урта төркем (кызлар), Вокал-соло (урта төркем (малайлар)», « Вокал-соло (өлкән төркем)», «Вокаль ансамбльләр (кече төркем)», «Вокаль ансамбльләр (урта төркем)», «Вокаль ансамбльләр (өлкән төркем)», «Хореография (кече төркем)», «Хореография (урта төркем)», «Хореография (өлкән төркем)», «Конферанс (кече төркем)», « Конферанс (урта төркем)», « Конферанс (зурлар төркеме)» номинацияләрендә соңгы өч елда (1,2,3 призлы урыннар) алучылар булу;

агымдагы елда әлеге педагогик хезмәткәрнең берләшмәсендә укучылар контингентының сакланышы;

укучыларның соңгы өч елда яшәү урыны буенча, яисә республикада үткәрелгән социаль юнәлешле конкурс чараларында, хәйрия концертларында катнашуын тәэмин итү.

2.3. Өстәмә белем бирү мәгариф оешмасында эшчәнлек алып баручы иң яхшы методистларны «Өстәмә белем бирүнең иң яхшы методисты» номинациясендә грант алуга конкурс нигезендә сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

соңгы өч елда өстәмә белем бирү оешмаларында белем бирү процессын программалы-методик тәэмин итү сыйфаты;

өстәмә белем бирү оешмаларының иң яхшы өстәмә белем бирү учреждениесе бәйгеләрендә катнашуын методик яктан тәэмин итү;

грантка дәгъва кылучының соңгы өч елда төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык конкурсларында катнашу нәтиҗәлелеге;

методистның инновацион, тәҗрибә экспериментал эшчәнлектә катнашуы;

грантка дәгъва кылучының соңгы өч елда үз педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү (оештыру, чыгышлар һәм публикацияләр) буенча чараларда (фәнни-гамәли конференцияләрдә, укыту семинарларында, мастер-классларда) катнашуы;

фәнни-методик эшчәнлектә катнашу, соңгы өч елда фәнни басмаларда материаллар бастыру;

өстәмә белем бирү оешмасының. үз эш юнәлеше буенча, муниципаль, региональ яисә федераль масштабта уздырылган стажер мәйданчыклары, семинарлар, мастер-класслар һәм башка чараларда катнашуы.

2.4. «Тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре номинациясендә (Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсе кадрларының һөнәри осталык республика конкурсы кысаларында) грант алуга конкурс сайлап алуы түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

«Ел укытучысы», «Йөрәгемне балаларга бирәм» һөнәри осталык республика конкурсы кысаларында 1, 2 һәм 3 нче урын

«Кеше тәрбияләргә», «Ел укытучысы» республика һөнәри осталык конкурсы кысаларында «Сыйныф җитәкчесе» номинациясендә 1, 2 һәм 3 нче урын

«Кеше тәрбияләргә», «Ел укытучысы» республика һөнәри осталык конкурсы кысаларында «Педагог оештыручы» номинациясендә 1, 2 һәм 3 нче урын

«Кеше тәрбияләргә», «Ел укытучысы» республика һөнәри осталык конкурсы кысаларында «Гомуми белем бирү оешмасының тәрбия эше буенча директор урынбасары» номинациясендә 1, 2 һәм 3 нче урын

«Ел укытучысы» республика конкурсы кысаларында «Йөрәгемне балаларга бирәм» һөнәри осталык конкурсында лауреат исеме;

«Кеше тәрбияләргә», «Ел укытучысы» республика һөнәри осталык конкурсы кысаларында «Сыйныф җитәкчесе» номинациясендә лауреат исеме;

«Кеше тәрбияләргә», «Ел укытучысы» республика һөнәри осталык конкурсы кысаларында «Педагог оештыручы» номинациясендә лауреат исеме;

«Ел укытучысы» республика конкурсы кысаларында үткәрелгән «Тәрбия өлкәсендә иң яхшы җитәкче» республика һөнәри осталык конкурсында «Тәрбия эше буенча директор урынбасары» номинациясендә лауреат исеме.

2.5. Иң яхшы педагог-оештыручы номинацияләрендә грант алу өчен иң яхшы педагог-оештыручыларны конкурс нигезендә сайлап алу түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

балалар һәм яшүсмерләр иҗтимагый оешмалары, берләшмәләр, укучылар үзидарәсе органнары эшчәнлегендә катнашучы укучылар өлеше
( % );

укучыларның соңгы өч елда төрле дәрәҗәдәге социаль-педагогик юнәлештәге конкурс чараларында, фестивальләрдә катнашуын тәэмин итү;

укучыларның төрле дәрәҗәдәге социаль педагогик юнәлештәге соңгы өч елда үткәрелгән конкурс чараларында катнашу нәтиҗәлелеге;

педагогик хезмәткәрнең инновацион эшчәнлектә катнашуы, эксперименталь эш алып бару, балалар иҗтимагый оешмалары һәм укучылар үзидарә органнары эшчәнлегенә яңа технологияләр һәм эш формаларын кертү;

педагогик хезмәткәрләрнең методик берләшмәләре эшендә, мәгариф процессын программалы-методик тәэмин итүдә, соңгы өч елда төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык бәйгеләрендә катнашуы;

проект эшчәнлегендә катнашу, балалар иҗтимагый берләшмәсен үстерүгә грантлар җәлеп итү;

педагогик хезмәткәрнең соңгы өч елда үз һөнәри эшчәнлегенең практик нәтиҗәләрен тарату буенча чараларда катнашуы (мастер класслар, тренинглар, семинарларда, вебинарларда, педагогик укуларда конференцияләрдә, докладлар).

2.6. Психологик-педагогик хезмәтнең иң яхшы педагог-психологы « номинациясендә Татарстан Республикасы мәгариф системасы белем бирү оешмаларында белем бирү процессы субъектларына психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы муниципаль психологик-педагогик хезмәтләрнең һәм психологик үзәкләрнең педагог-психологларына ярдәм күрсәтү буенча Гранг алырга конкурс түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә::

педагог-психолог психологик десантта эшләү күләме һәм сыйфаты;

педагог-психологның инновацион эшчәнлектә катнашуы, эксперименталь эш алып баруы (расланган сертификатлар булу);

педагог-психологның соңгы өч елда төрле дәрәҗә һөнәри осталык бәйгеләрендә катнашу нәтиҗәлелеге;

психологик-педагогик ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән грантларда катнашу;

укучылар, студентлар, педагоглар, ата-аналар өчен психологик белем бирү системасы, бу эшнең формалары һәм актив методлары (семинарлар, факультативлар, эшлекле уеннар, психолог стенды һәм тд .п.) булу;

педагог-психологның соңгы өч елда үз психологик-педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү (чыгышлар һәм публикацияләр) буенча чараларда (фәнни-гамәли конференцияләр, семинарлар, мастер-класслар) катнашуы;

клиентларның әлеге белгеч эше турында уңай фикерләре;

педагог-психологның педагогик карарларга психологик экспертизаларда, программаларда, конкурс комиссияләрендә, чыгарылыш һәм кабул итү имтиханнарында катнашуы, эшкә алганда, педагогик кадрларны аттестацияләүдә катнашуы.

2.7. «Дәүләт бюджет белем бирү оешмасының иң яхшы педагог-психологы» номинациясендә урта гомуми белем бирү, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының, балалар йортлары, караучысыз калган балаларны гаиләләргә урнаштыру, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының дәүләт белем бирү оешмаларында белем бирү процессында катнашучы субъектларга педагогик-психологик ярдәм күрсәтүче педагог-психологлар арасыннан грант алуга конкурс түбәндәге критерийлар нигезендә үткәрелә:

педагог-психологның инновацион эшчәнлектә катнашуы, эксперименталь эш алып бару (раслаучы сертификатлар булу);

педагог-психологның соңгы өч елда төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык бәйгеләрендә катнашу нәтиҗәлелеге ;

психологик-педагогик ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән грантларда катнашу;

педагог-психологның соңгы өч елда үзенең психологик-педагогик тәҗрибәсен гомумиләштерү буенча чараларда (фәнни-гамәли конференцияләрдә, укыту семинарларында, мастер-классларда) катнашуы;

клиентларның әлеге белгеч эше турында уңай фикерләре;

диагностика реабилитация һәм балаларга ярдәм итүче башка үзәкләр, психология кафедралары, квалификация күтәрү институтлары белән хезмәттәшлек;

педагог-психологның психологик экспертизаларда, конкурс комиссияләрендә, чыгарылыш имтиханнарында, эшкә кабул иткәндә әңгәмәләрдә, педагогик кадрларны аттестацияләүдә катнашуы;

укучыларны, педагогларны, ата-аналарны психологик (агарту) белем бирү системасы, бу эшнең формалары һәм актив методлары (семинарлар, факультативлар, эшлекле уеннар, психолог стенды һ. б.) булу;

белем бирү учреждениесенең, дәүләт бюджет оешмасының тормышында психологның катнашуы дәрәҗәсе;

коллективта уңай психологик климат булдыру (белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлы ситуацияләр булмау).

2.8. Һөнәри белем бирү оешмасының тәрбия эшләре буенча иң яхшы директор урынбасары номинациясендә грант алуга иң яхшы һөнәри белем бирү оешмалары директорларын конкурс нигезендә сайлап алу 2016-2017 уку елында һөнәри белем бирү оешмаларының рейтинг нәтиҗәләре нигезендә үткәрелә:

гражданлык-патриотик тәрбия чараларында һөнәри белем бирү оешмасының катнашу нәтиҗәлелеге күрсәткече;

студентлар үзидарәсе органының һөнәри белем бирү оешмасының эш нәтиҗәлелеге күрсәткече;

һөнәри белем бирү оешмасының сәламәтлекне саклау һәм спорт сәламәтләндерү хезмәте эшенең нәтиҗәлелеге күрсәткече;

2016-2017 уку елында мәдәни-массакүләм чараларда һөнәри белем бирү оешмасының катнашу нәтиҗәлелеге күрсәткече;

һөнәри белем бирү оешмасы укучыларының хокук бозуларын профилактикалау хезмәте эшенең нәтиҗәлелеге күрсәткече;

һөнәри белем бирү оешмасында тәрбия эшенең төп юнәлешләре нигезендә методик һәм планлаштыру документлары булу.

## 3. Грант алуга конкурс сайлап алуны үткәрү тәртибе

3.1. Грант алуга Конкурс Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә.

3.2. Грант бирүче. гаризалар кабул итү вакыты тәмамланырга 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе сайтында (алга таба ДБУ «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге») мәгълүмат урнаштыру юлы белән конкурс үткәрү турында игълан итә.

3.3. Грантка тәкъдим итү гариза бирүчеләрнең ризалыгы белән һәм үз-үзен тәкъдим итү юлы белән үткәрелә.

3.3.1. 2017 елның 30 маена һәм 10 июненә кадәр, әлеге Положениенең 1 нче кушымтасы нигезендә гариза бирүченең грантка дәгъва кылучыны тәкъдим итү турында нигезләмәсе түбәндәге адрес буенча тапшырыла

«Өстәмә белем бирүнең иң яхшы методисты», «Өстәмә белем бирүнең иң яхшы педагогы «, «Иң яхшы педагог-оештыручы», «Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсенең иң яхшы хезмәткәре» номинациясе 2017 елның 30 маена кадәр «Грант, номинация _____________» тамгасы белән, 420036, Казан шәһәре, Тимирязев ур., 8а йорт., а/я 36, ДБУ Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге;

«Өстәмә белем бирү оешмасының иң яхшы директоры», «Һөнәри белем бирү оешмасының тәрбия эше буенча иң яхшы директор урынбасары» номинациясе 2017 елның 10 июненә кадәр «Грант, номинация _____________» тамгасы белән 420036, Казан шәһәре, Тимирязев урамы, 8а йорт, а/я 36, ГБУ Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге

«Психологик-педагогик хезмәтнең иң яхшы педагог-психологы», «Белем бирү оешмасының, дәүләт бюджет оешмасының иң яхшы педагог-психологы» номинациясе 2017 елның 30 маена кадәр, «Грант, номинация _____________»

тамгасы белән, 420057, Казан шәһәре, Ак Королев урамы, 4Б йорт, дәүләт автоном белем бирү учреждениесе « Росто» республика психологик-педагогик ярдәм үзәге».

3.2. Грант алуга конкурс материаллары 2017 елның 30 маеннан һәм 10 июненнән соң кабул ителми.

3.3. Грант алуга конкурс материаллары рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

3.4. Грантка тәкъдим итүгә мөрәҗәгатькә кушымта итеп түбәндәге документлар бирелә:

Грантка дәгъва кылучының профессиональ белеме турында, эш бирүче тарафыннан расланган, диплом күчермәсе ;

Грантка дәгъва кылучының эш урыныннан, эш бирүче тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе, яисә әлеге вазыйфада стажы кимендә өч ел тәшкил итүен раслаучы белешмә,

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә дәгъва кылучының ризалыгы (2 нче кушымта);

муниципаль һәм (яки) республика дәрәҗәсендәге Һөнәри берләшмәләрнең үтенечнамәсе;

әлеге Положениенең 2 бүлегендә күрсәтелгән критерийлар нигезендә, эш бирүче яки гамәлгә куючы тарафыннан расланган, Грантка дәгъва кылучының һөнәри казанышлары турында, исбатлаучы документларны теркәп, мәгълүмат;

грантка дәгъва кылучы тарафыннан экспертиза өчен республика комиссиясенә тәкъдим ителгән документлар исемлеге (3 нче кушымта).

3.5. Конкурс материалларын кабул итү, теркәү Республика комиссиясе тарафыннан башкарыла.

Кабул иткәндә Грантка дәгъва кылучының документларына теркәү номеры куела.

Һәр Грантка дәгъва кылучыга республика комиссиясенә тапшырылган документларга техник экспертиза бәяләмәсе (4 нче кушымта) формалаштырыла.

3.6. Грант алуга конкурс сайлап алуы Конкурс һәм һәр номинация буенча эксперт төркемнәре катнашында, бирелгән документларга читтән торып, әлеге

Положениенң 2 бүлегендә билгеләнгән критерийлар нигезендә, баллар бирү юлы белән үткәрелә.

3.7. Һәр критерий буенча, Республика комиссиясе тарафыннан, баллар саны 5 баллы шкала буенча билгеләнә (0-5).

3.8. Грант алырга тәкъдим ителгән документларга экспертиза үткәрү өчен Республика комиссиясе тарафыннан эксперт төркемнәре составы формалаштырыла, Министрлык боерыгы белән раслана. Боерык, расланган көнне үк, Министрлык һәм ДБУ Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге рәсми сайтларында урнаштырыла.

3.9. Грантка дәгъва кылучыларның документларына экспертиза нәтиҗәләре буенча эксперт бәяләмәсе төзелә, экспертиза үткәргән экспертлар тарафыннан имзалана.

3.10. Грант алуга конкурс нәтиҗәләре нигезендә, Республика комиссиясе грантның һәр номинациясе буенча, грантка дәгъва кылучыларның рейтинг исемлеген төзи. Республика комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча, дәгъва кылучыларның рейтинг исемлекләре кушымтасы белән, протокол төзелә.

3.11. Бер үк төрле балл җыйган һәм рейтингның түбән чигендә урнашкан грантка дәгъва кылучылар булганда, Республика комиссиясе документларга өстәмә экспертиза оештыра.

3.12. Өстәмә экспертиза нәтиҗәләре эксперт бәяләмәсендә һәм Республика комиссиясе беркетмәсендә чагылдырыла. Республика комиссиясе беркетмәсе нигезендә дәгъва кылучылар рейтингына кирәкле үзгәрешләр кертелә.

3.14. Республика комиссиясе 1.6.2 пунктында һәр номинация өчен билгеләнгән квота нигезендә Грант алучылар исемлеген төзи һәм аны Министрлыкка раслауга тәкъдим итә..

3.15. Тәкъдим ителгән исемлек нигезендә Министрлык грант нәтиҗәләре турында Грант алучылар исемлеген раслаган приказ чыгара. Грант нәтиҗәләре турында боерык расланган көндә, Министрлыкның, ДББУ «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге» һәм «Росток «психологик-педагогик тәэмин итү буенча республика үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең рәсми сайтларында бастырыла.

3.16 Грант алуга конкурс нәтиҗәләре һәр грант алучыга, Грант нәтиҗәләре турында боерык чыккан көннән 3 эш көне эчендә, шәхси электрон яки почта адресларына язма хәбәр итү юлы белән җиткерелә.

3.17. Конкурс нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, грантка дәгъва кылучы грант бирү буенча республика комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция белән гариза, нәтиҗә игълан ителгәннән соң, 10 эш көне эчендә, республика комиссиясе рәисе исеменә ирекле рәвештә бирелә.

3.18. Республика комиссиясе апелляцияне 7 эш көне эчендә карый. Апелляция буенча республика комиссиясе карарлары комиссия составыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, республика комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч хокукына ия. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча республика комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәрешсез калдыру турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм гант алуга конкурс нәтиҗәләрен үзгәртү турында.

3.19. Конкурс материалларын бәяләү критерийлары апелляция предметы була алмый һәм яңадан каралырга тиеш түгел.

3.20. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча Реепублика комиссиясе карарлары ахыргы булып тора һәм яңадан карап тикшерелә алмый.

3.21. Республика комиссиясе тарафыннан апелляцияне карау республика комиссиясе рәисе һәм барлык әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

## 4. Грантны гамәлгә ашыру буенча республика комиссиясе һәм эксперт төркемнәре

4.1. «Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» грантын гамәлгә ашыру буенча Республика комиссиясе һәм эксперт төркемнәре Грантка конкурс нигезендә сайлап алу буенча даими эшләүче орган булып торалар һәм Министрлык боерыгы белән расланалар.

4.2. Республика комиссиясе Грант алучыларның рейтинг исемлеген төзи һәм раслый.

4.3. Грантны гамәлгә ашыру буенча эксперт төркемнәре (алга таба  эксперт төркемнәре) хокуклы:

бәйсез эксперт төркемнәре карамагына кертелгән мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

кирәк булганда конкурс материалларына өстәмә экспертиза үткәрү өчен белгечләрне җәлеп итәргә;

грант алырга теләүче  педагогик хезмәткәрләр белән анкеталар үткәрергә.

4.4. Республика комиссиясе һәм эксперт төркемнәре утырышлары кирәк булган саен уздырыла һәм,   алар  составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы булып санала.

4.5. Республика комиссиясе һәм эксперт төркемнәре карарлары, әгәр алар өчен исемлек составының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышларның тигез булган очракта Республика комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

4.6. Грант алучылар исемлеген килештерү турындагы карар тиешле эксперт Подкомиссиясенең утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.7. Республика комиссиясе составында 8 әгъза.

4.8. Эксперт төркемнәре составында 3 әгъза һәм алар агымдагы елда үзләре Грантка дәгъва кылучылар булырга тиеш түгел.

**5. Грантны Финанслау**

5.1. Грант бирү өчен  субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

**Кушымта №1**

Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү

өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты турында Положениегә

| |
|---|
| Теркәлү номеры: № _____________ |
| Гаризаны теркәү датасы:____________ |

## ГРАНТКА ГАРИЗА БИРҮЧЕНЕҢ ГРАНТКА ДӘГЪВА КЫЛУЧЫЛАР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАРЫ

**Грантка дәгъва кылучы турында белешмә**

Номинация (өстәмә белем бирү педагоглары өчен юнәлешне күрсәтергә)
___________________________________________________________________________

Ф. И. О.___________________________________________________________________

Туган көне ________________________________________________________________

Паспорт мәгълүматлары (номер, серия, кем һәм кайчан бирелгән)_______________________________________________________________

Прописка урыны буенча адрес _______________________________________________

ИНН______________________________________________________________________

Пенсия-иминият таныклыгы _________________________________________________

Акбарс Банк картасы номеры_________________________________________________

Элемтә өчен (кәрәзле) Грантка дәгъва кылучының телефоны:___________________

Эш урыны (Устав нигезендә белем бирү оешмасының тулы исеме)'.______________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Вазыйфасы (әлеге мәгариф оешмасында): ___________________________________

Мәгариф оешмасының почта адресы:______________________________________

Элемтә өчен телефон: ____________________ Факс: _________________________

E-mail: _______________________ htpp:___________________________________

Гомуми педагогик эш стажы әлеге вазыйфада, әлеге мәгариф оешмасында эш стажы: _______________________________________________________________

Мактаулы исемнәре:______________________________________________________

**<u>Гариза бирүче турында мәгълүмат</u>**

Мөрәҗәгать итүченең исеме (оештыру-хокукый форманы да кертеп)):

______________________________________________________________________________

Җитәкче Ф. И. О., вазифа:____________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең факттагы адресы: ________________________________________

Элемтә өчен телефон: _____________________   Факс:____________________________

**Мөрәҗәгать итүченең имзасы:_______________________________________________**

**М. П.**

Грантка дәгъва кылучыларга Грантка тәкъдим итү буенча мөрәҗәгать итүче оешма утырышы датасы, протокол № _______________________________________________

*Әгәр мөрәҗәгать итүченең печате булмаса, мөрәҗәгать итүченең имзасы әлеге оешма караган иҗтимагый органы җитәкчесе, тарафыннан. яисә мәгариф идарәсенең муниципаль бүлеге (идарә) җитәкчесе тарафыннан раслана*

**Кушымта №2**

Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү
өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты турында Положениегә

ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК

«_____» _______________ 20_____ г.

Мин, ____________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

серия №__________________________________________________________________

(шәхесне раслаучы документ төре)

бирелгән _________________________________________________________________

(кем һәм кайчан)

Адресы буенча яшәүче______________________________________________________

Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге (алга таба оператор) дәүләт бюджет учреждениесенә минем шәхси мәгълүматларны (Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләрен исәпкә алып, миннән һәм/яки теләсә нинди өченче затлардан) алу һәм эшкәртүгә ризалык бирәм һәм мин үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремә туры китереп эш итәм дип раслыйм.

Ризалык минем яктан Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр грантын оештыру комитетына документлар тапшыру буенча эш операторы тарафыннан бирелгән (алга таба Грант) грант акчаларының түләүләрен тәэмин итү өчен, 2006 елның 27 июлендәге Федераль законда каралган. Персональ мәгълүматлар турында « 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелә һәм түбәндәге мәгълүматларны куллануга кагыла: минем фамилиям, исемем, әтиемнең исеме, туган ел, ай, дата һәм туган урын, адрес, белемем, һөнәр һәм минем шәхесемә кагылышлы башка мәгълүматлар.

Әлеге ризалык югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәк булган шәхси мәгълүматыма карата кирәк булган гамәлләрне башкаруга, шул исәптән чикләүләрсез информацияне җыю, системага салу, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), шәхси мәгълүматларны куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шулай ук

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләрен исәпкә алып, минем шәхси мәгълүматлар белән теләсә нинди бүтән гамәлләр башкаруга бирелә.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү оператор тарафыннан түбәндәге төп ысулларны кулланып башкарыла (ләкин алар белән генә чикләнмичә): саклау, электрон носительләргә язылу һәм аларны саклау исемлекләр төзү.

Югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен шәхси мәгълүматлар бирү кирәк булган очракта, өченче затларга (шул исәптән Россия Мәгариф һәм фән Министрлыгы белән чикләнеп калмыйча), шулай ук өченче затларны минем мәнфәгатьләремдә хезмәт күрсәтүгә җәлеп иткәндә, оператор, югарыда күрсәтелгән гамәлләр башкару өчен шәхсән үзем (шәхси мәгълүматымны да кертеп) минем хакта мәгълүматны шундый өченче затларга тапшырырга, шулай ук мондый мәгълүматны үз эченә алган тиешле документларны (паспорт күчермәсе, хезмәт кенәгәсе күчермәсе) тапшырырга хокуклы.

Дата «______»_____________20____ г.

_____________________/__________________

подпись расшифровка

**Кушымта №3**

Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү

өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты турында Положениегә

| | |
|---|---|
| Теркәлү номеры: № _____________ | |
| Гаризаны теркәү датасы:____________ | |

**Гранка дәгъва кылучы тарафыннан республика комиссиясенә экспертиза өчен тапшырылган**

**ДОКУМЕНТЛАР ИСЕМЛЕГЕ**

| № | Документ/ конкурс материалы | Битләр саны |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүченең грантка дәгъва кылучыны тәкъдим итү турында аныклама | |
| 2 | Грантка дәгъва кылучының, Гариза бирүче тарафыннан расланган, профессиональ белеме турында диплом күчермәсе | |
| 3 | Грантка дәгъва кылучының хезмәт кенәгәсе күчермәсе, яисә әлеге эш урыныннан (эш бирүче тарафыннан расланган) әлеге вазыйфада кимендә өч ел стажы булуын раслаучы белешмә | |
| 4 | Грантка дәгъва кылучының шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы | |
| 5 | Республика яисә муниципалҗ дәрәҗәсендәге Һөнәри бергәлекләр яисә иҗтимагый оешма үтенечнамәсе | |
| 6 | Грантка дәгъва кылучының һөнәри казанышлары турында (эш бирүче тарафыннан расланган) мәгълүмат | |
| 7 | Башка документлар (беркетмәләр, таныклыклар сертификатлар, дипломнар (эш бирүче тарафыннан расланган) күчермәләре | |

Барлыгы __________________ бит

Тапшырды (Ф. И. О., вазыйфа, эш урыны_____________________________

________________________________________________________________

Имза: _______________

Дата: ________________________

Кабул итте (Ф. И. О., вазифасы, эш урыны):_____________________________

________________________________________________________________

Имза: ____________________

Дата: _________________________

**Кушымта №4**

Балаларга тәрбия һәм өстәмә белем бирү

өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр гранты турында Положениегә

| |
|---|
| Теркәлү номеры: № _____________ |
| Гаризаны теркәү датасы:____________ |

**Грантка дәгъва кылучы тарафыннан республика комиссиясенә тапшырылган ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ТЕХНИК ЭКСПЕРТИЗАСЫ НӘТИҖӘСЕ**

| № | Документ/ конкурс материалы исеме | Кабул ителгән | Кабул ителмәгән |
|---|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүченең грантка дәгъва кылучыны тәкъдим итү турында аныклама | | |
| 2 | Грантка дәгъва кылучының профессиональ белеме турында Гариза бирүче тарафыннан расланган диплом күчермәсе | | |
| 3 | Грантка дәгъва кылучының хезмәт кенәгәсе күчермәсе, яисә әлеге эш урыныннан (эш бирүче тарафыннан расланган) әлеге вазыйфада кимендә өч ел стажы булуын раслаучы белешмә | | |
| 4 | Грантка дәгъва кылучының шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы | | |
| 5 | Республика яисә муниципалдь дәрәҗәсендәге Һөнәри бергәлекләр яисә иҗтимагый оешма үтенечнамәсе | | |
| 6 | Грантка дәгъва кылучының һөнәри казанышлары турында (эш бирүче тарафыннан расланган) мәгълүмат | | |
| 7 | Башка документлар (беркетмәләр, таныклыклар сертификатлар, дипломнар (эш бирүче тарафыннан расланган) күчермәләре | | |

| **Техник экспертиза нәтиҗәләре** | |
|---|---|
| Техник экспертизасы буенча грант алуга рөхсәт ителә | Техник экспертизасы буенча грант алуга рөхсәт ителми |

Эксперт_________________ /__________________ дата_____________